

Мәгариф системасында элек-электән кvпсанлы һонәрләр белән таныштыруга һәм vсеп килvче буынга һонәр сайлау-да ярдәм кvрсәтvгә юнәлдерелгән чаралар системасы эшләп килә. Предприятиегә экскурсия- балаларны житештерv һәм һонәрләр нигезләре белән таныштырунын ин нәтижәле формаларынын берсе. Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе укучылары, укытучылары житәкчелегендә, Латышовка авылы хормәтле һәм мактаулы фермер-житәкче Рушан Зариф улы Поташов авыл хужалыгы предприятиесенә мавыктыргыч һонәри юнәлеш бирv экскурсиясен алып барды. Олкән сыйныф укучылары заманча авыл хужалыгы техникасы белән таныштылар һәм аграр тармактагы эш турында бик кvп кызыклы нәрсәләр белделәр. Рушан Зариф улынын эчтәлекле һәм мавыктыргыч экскурсиясе очен рәхмәтләрен белдергән укучылар киләчәктә зур корабларга утырып халкыбызны ипи белән тәэмин итv профессиясе турында уйланып таралыштылар.



Сойләгәнне тынлаганчы бер кvрv артыграк, диләр бездә картлар.
Профориентацион проект кысаларында Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе олкән сыйныф укучылары, мәктәп директоры Надия Харис кызы Заликова vзе- нен завучы Эльвера Хәмзә кызы Ахметова, шулай ук Татар Тавла топ мәктәбе укучылары, мәктәп завучы Рима Хәмзә кызы Ряхмятуллова белән чын сабын заводында – «Экотавла»да булганнар.
Сабын заводына бару- хуш исләр, табигый ингредиентлар һәм ижат доньясына чуму. Укучылар башта сабын ясау тарихы белән танышканнар, сабын ясау процессын vз кvзләребез белән кvргәннәр, аннары хуш исле сувенир булдырып, уникаль проектны булдырган Айдар Фаиль улы Шафеев белән Радик Раиль улы Аксянов мастер-классында катнашканнар.
Экскурсиядә катнашучылар әлеге авыр, игелекле хезмәтләре очен аерым рәхмәтләрен белдереп, сабын ясау процессы белән танышулыры очен шат булып киләчәк турында уйлануларын белдерделәр: сабын ясаучылар кебек кешеләр башкаларга омет бирә, андый кешеләр башкаларны кочлерәк һәм игелеклерәк итә. Хуш исле мажара: сабын заводында бер кон - киләчәккә билет.



Айдар Фаиль улы Шафеев очрашу турында: «Бу безнен беренче тәжрибәбез иде, һәм, доресен генә әйткәндә, бераз дулкынландык. Ләкин егетләр шулкадәр кызыксынучан һәм актив булып чыктылар - барысы да бик яхшы узды!
Табигый сабыннын ничек әзер-ләнvен - ингредиентларны катнаштырудан алып әзер бруска кадәр сойләдек һәм кvрсәттек. Эш башлау тарихы - барысы да нәрсәдән башлануы, беренче vрнәкләр һәм бvгенге нәтижәләребезгә ничек килvебез белән

уртаклаштык. Сабын торv буенча зур булмаган мастер-класс уздырдык - һәркем vзен эштә сынап карый алды һәм нәтижәлә-рен vзләре белән алып киттеләр. Мәктәп администрациясенә һәм укытучыларга ышанычлары, оештырулары һәм жылы кабул итvләре очен, ә балаларга жанлы кызыксынулары һәм елмаюлары очен рәхмәтебезне белдерәбез. Сезгә дә безнен кебек vк кызык булгандыр дип ометләнәбез. Мондый очрашулар эшебезне кvнелле дәвам итәргә рухландыра.»

**Наилә НАСЫРОВА**